ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 18** **04 август 2015 ел**

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле
авыл җирлеге Башкарма комитетының
2015 елның 27 фервлаендәге 8 санлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 22 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 431-ФЗ санлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында»гы ПУ-308 санлы Указы нигезендә һәм коррупциягә каршы тору буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында, Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 27 фервлаендәге «Гражданнар билгеләгәндә һәм аларны алмаштырганда муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында»гы 8 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) атамасында, преамбуласында, 1 пунктында, «гражданнар билгеләгәндә һәм " сүзләрен алып ташларга;

б) муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегендә гражданнарны билгеләгәндә һәм аларны алмаштырганда муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев